ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.10.2025 с.Старое Дрожжаное № 371

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында Чуаш Бизнәсе-Татар Бизнәсе» автомобиль юлын төзү» объекты территориясен планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча документацияне раслау турында

“Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү буенча баш идарәсе” ДКУ мөрәҗәгате буенча дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен тартып алу эшләрен тәгалләү зарурлыгына бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының 56.3 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында Чуаш Бизнәсе-Татар Бизнәсе» автомобиль юлын төзү» объекты территориясен планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча документацияне үзгәрешләрсез расларга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 01 июнендәге 287 номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында Чуаш Бизнәсе-Татар Бизнәсе» автомобиль юлын төзү» объекты территориясен планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча документацияне раслау турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р. Баһаутдиновка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов